Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № LIII-5**

Балык Бистәсе штп. 2024 елның 17 декабре

Җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:

- мәет җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру;
- мәет җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү;
- мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегендәге хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатына карата таләпләрне раслау;
- мәет җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау;
- ире, якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булган кешенең законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкин булмаганда вафат булганнарны (һәлак булганнарны) җирләүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау, шулай ук өйдә, урамда яисә шәхесенең эчке эшләр органнары билгеләгәннән соң башка урында үлгән кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда;
- шәхесе Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокларда эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнмәгән үлгәннәрне (һәлак булганнарны) җирләүгә хезмәт күрсәтү бәясен раслау.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына:

- Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;
- әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында бюджет законнары нигезендә 2025 елга һәм 2026 – 2027 еллар план чорына Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары проектында финанслауны күздә тотарга.

3.Карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов